

Үз эшен яраткан һәм кадерен белгән кеше турында, Азат Рафаэль улы Салякаев турында сvзебез. Ул шактый яшь, утызны тутырган, әмма инде хөрмәткә лаек эше байтак.
Ләмберә малае Азат Рафаэль улы 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнан сон пешекче-машина йортvче белгечлеген сайлап, Ләмберәдәге СПТУга укырга керергә карар кыла. Бу уку йортын тә-мамлаганнар берьюлы ике белгечлек - пешекче һәм машина йортvче турында ике документ ала торган булганнар. Тик язма героебызга ике документ алырга насыйп булмый, чонки уку барышында автомобиль краннары машинисты әзерли торган бvлеккә кvчәргә тәгъдим итәләр. Укытучылары бу адымны финанс яктан кирәк, отышлырак һәм кон таләбе дип дәлилли.

Азат риза була һәм бер тапкыр да бу хакта vкенми. Дипломынын «специальность» графасында - машинист автомобильного крана, дип язылган.
Бvген профессиональ техник белемнен роле турында сойләшvләр кvп. Хәзер эшче белгечләр югары белемле кадр-ларга караганга ихтыяж кvпкә артыграк. Еш кына производстволарга токарьлар, фрезерчылар, слесарь - лекальщиклар кирәк дигән белдерvләргә тап булабыз. Әлбәттә, иске мәгариф системасына тулы кvләмдә кире кайту булмаячак, бу анлашыла да инде, чонки ишегалдында башка вакытлар, башка чынбарлыклар. Әмма безгә совет һонәри белем елларындагы тәжрибә белән бvгенге гасырга да атлау гонаһ булмас иде. Чонки, әйтик, СПТУ-14 нәкъ менә шул вакытта формалашкан һәм vз әһәмиятен vстергән. Училище ветераннары да укучыларына бәяләп бетергесез белем тапшырган. Әйтик, Азат Рафаэль улы Салякаев училищеда укуын, педагогларын ихлас кvнелдән искә ала. Беренче классы остазы Михаил Федорович Борисов кебекләрне кvбрәк сагына. Белгәнебезчә, һонәри техник белемлеләр -

производствонын нигезе. Училище квалификацияле кадрларнын чын тимерчесе була ул заманда.
Укуны тәмамлап кулына белгечлек кенәгәсен алган Азат Рафаэль улы Салякаев хәрби хезмәттә тозелеш гаскәрләренә эләгә: аэродромдагы очыш полосасына хезмәт кvрсәтә. Биредә эш житәрлек булган; кондез дә, тонлә дә чыгып китәргә туры килгән. Шуна да Азат Рафаэль улы оенә тәжрибәле кранчы, vткен белгеч булып кайта. СПТУны тәмамлаган иптәшләре кvбесе vз тормышларын бу һонәр белән бәйләмәгән, ә Азат анын белән аерылмаган. Армиядә хезмәт итеп кайткач, кәсеб эзләп, Сочига эшләргә, курорт-шәһәрне кышкы олимпиадага әзерләргә киткән һәм Олимпияда авылында яшәгән дә. Биредә ана ошаган. Вахта ысулы белән эшләгән: бер ай - Сочида, бер ай – Ләмберәдә. Олимпиаданы кабул итvче шәһәрдә эшләv киләчәктә зур перспективалар тудырган, зур эш тәжрибәсе туплаган. Бәлки ул анда калыр иде дә, әмма Ләмберәдә аны мәхәббәте коткән. Мәхәббәтләре кавышу белән йомгакланган. Шул вакыттан алып Азат республикабызга «ябыша» һәм аннан читкә чыкмый. Монда да эш житәрлек. «Кайда туган, анда файдалы да булган» дип юкка гына әйтмиләр. Азат Рафаэль улынын эш тартмасында Рузаевка районынын Красное Сельцо авылында мәктәп тозv; уку елы башына олгерергә, ашыгырга кирәк була. Тозvчеләр сынатмыйча намус белән эшлиләр. Мәктәпне ачу тантанасында аларнын кvбесе Рузаевка районы администрациясе башлыгы кулыннан бvләкләр алалар: Азатнын бу грамотасы әле дә саклана. А.Р.Салякаевка халык хужалыгынын кvп кенә тозелешләрендә эшләргә туры килә. Объектлар гел vзгәреп тора: бvген син Саранскида асфальт заводы жыясын, ә бер атнадан Торбеево районында урнашкан елгага бетон слив куясын. Биредә билгеле бер романтика да бар. Анын һонәре тормыш очен куркынычлы. Әлбәттә, бу манара кран машинисты тvгел, әмма Азат Салякаев эшендә бик кvп аяныч очраклар да була. Мәсәлән, техникасы кабинасында машинист ауланып тошкән очракларны кvргәне бар. Бу машинаны кран белән ныгыткан ригель туфракка бәрелгәч, машинаны баткаклык суыра башлый, йок авыша һәм техника егыла. Азатны шундый очраклардан Аллам vзе саклаган, әмма анын кvз алдында коллегалары белән шундый хәл булган. Бәхеткә, беркем дә жәрәхәтләнмәгән. Осталыгы белән танылган кеше турында дан тирә-юньдә дә, еракта да ишетәләр. Рафаэль улы Азатка Торбеево районы Дракино авылындагы Изге Покровский ирләр монастырендә ашыгыч эш тәкъдим иттәләр - купель ясаталар. Техник яктан катлаулы купель нигезен урнаштыру, монтажлау югары дәрәжәдә оста һәм вакытында башкарыла. Ихтирам йозеннән Игумен Пахомий Азат Салякаевка бер банкка бал бирә. «Бvләкнен кvләме кадерле тvгел, - ди Азат, - ә игътибар, хормәт кадерле. Алар сина ихластан бvләк иткәч, ничек кире кагарсын инде?»
Ул һонәрен vзгәртергә теләми дә, чонки хезмәте ана ошый, барысы да канәгатьләндерә; шуна кvрә башка вариантларны карамый да.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**